СӨЙ ГОМЕРНЕ, СӨЙ ХАЛЫКНЫ, СӨЙ ХАЛЫКНЫҢ ДӨНЬЯСЫН!

# ДУСЛЫК

ОКТЯБРЬ РАЙОНЫ ИҖТИМАГЫЙ - СӘЯСИ ГАЗЕТАСЫ.
ОБЩЕСТВЕННО-ПОЛИТИЧЕСКАЯ ГАЗЕТА ОКТЯБРЬСКОГО РАЙОНА.

19 сентябрь, 1997ел. ҖОМГА

Газета 1931 елның 9 июленнән бирле чыга. № 105 (8117) Бәясе билгеләнгәнчә

## Күздән сөрсәк, язын җиңел булыр

***Саннарның беренче баганасы - район хуҗалыкларында 17 сентябрьгә туңга сөрү планының үтәлеше (процентларда), икенчесе - соңгы алты көндә туңга сөрелгән мәйдан (гектарларда)***

| | | |
|---|---|---|
| «Таң» | 71 | 152 |
| «Дуслык» | 64 | 55 |
| Мичурин исем. | 62 | 350 |
| «Рассвет» | 61 | 173 |
| «Якты Күл» | 60 | 59 |
| «Чирмешән» | 60 | 227 |
| «Родина» | 56 | 100 |
| «Заветы Ильича» | 54 | 94 |
| Синдряков исем. | 53 | 388 |
| «Агрохимсервис» ярд. хуҗ. | 53 | 100 |
| «Киекле» | 51 | 750 |
| «1 нче Май» | 50 | 244 |
| Кузнецов исем. | 50 | 335 |
| М.Җәлил исем. | 48 | 255 |
| «40 лет Победы» | 48 | 140 |
| Хафизов исем. | 45 | 170 |
| «Кондырча» | 45 | 118 |
| Нефтебаза ярд. хуҗ. | 45 | 270 |
| МСО ярд. хуҗ. | 45 | 115 |
| Сөт - май комб. ярд. хуҗ. | 45 | - |
| РСУ ярд. хуҗ. | 45 | 135 |
| «Алга» | 44 | 480 |
| «Заря» | 44 | 110 |
| «Төрнәс» | 42 | 130 |
| Агробанк ярд. хуҗ. | 42 | - |
| «Әлмәт» | 36 | 416 |
| «Үрнәк» | 34 | 295 |
| «Игенче» | 33 | 145 |
| Шикәр заводы ярд. хуҗ. | 31 | 120 |
| «Татарстан» | 31 | 250 |
| «Комбайн» | 28 | 150 |
| **Район буенча** | **47** | **6226** |

***

Туңга сөрү кебек җаваплы да, шул ук вакытта гаять авырлык белән бирелә торган эшнең темплары һаман да канәгатьләнерлек түгел әле. Соңгы бер көндә район буенча сөрелгән мәйданнар мең гектарга да тулмады. Кайбер хуҗалыкларда туңга сөрүдәге техниканың җитештерүчәнлеге гаять түбән. Аерым алганда, «Игенче», «Комбайн»,«Заря», «Татарстан», «Кондырча»да, МСО һәм «Агрохимсервис» ярдәмче хуҗалыкларында соңгы бер көндә фәкать 10 - 25 гектар җир эшкәрттеләр. Ә «Төрнәс»тә, сөт - май комбинатының ярдәмче хуҗалыгында бу мәсьәләгә караш бөтенләй аңлашылмый. Әле хуҗалыкларның барысында да диярлек промышленность предприятиеләреннән ярдәмгә тартылган техника барында аларны ничек тә нәтиҗәлерәк файдаланып калу турында кайгыртырга кирәк. Туңга сөрүне болай озакка сузу язын үзен бик нык сиздерергә мөмкин бит.

● *Безгә язалар*

## Эшчәнгә эш бетәмени

Исеме районга билгеле комбайнчы Александр Егорович Донсков үзе эшли торган Хафизов исемендәге хуҗалык кырларында чакта ук районда урак лидерлары сафында барган иде. Үзләрендә урак тәмамлангач «Игенче» хуҗалыгына ярдәмгә килде ул һәм анда да 2650 центнер ашлык суктырып, бу сезонда егерменче мең центнерын тутыра язды. Инде МСОның ярдәмче хуҗалыгы кырларына күчкән уңган комбайнчының өченче дистә мең центнерга да исәп ачасына шикләнмәскә мөмкин.

## Норма арттырып үтәлә

«Чирмешән» хуҗалыгы туңга сөрүдә районда алдынгылар сафында бара икән, монда хуҗалыкның уңган механизаторлары Әхәт Барый улы Сөнгатуллин белән Тәбрис Мөбәрәкша улы Садыйковларның да өлеше зур. Аларның беренчесе К- 700 тракторында көнгә 13әр гектар җир эшкәртеп смена нормасын 180 процентган күбрәккә, икенчесе Т - 150 белән 10 гектарга кадәр җир сөреп норманы 170 процентган артыгракка үти.

## Чөгендергә төштеләр

«Рассвет» КХАсы менә инде өч ел рәттән шикәр чөгендерен француз технологиясе буенча игә. Өч ел рәттән плантацияләрдән уңыш үзвакытында, югалтуларсыз җыеп алына. Уңыш та елдан-ел арта.

Быел биредә шикәр чөгендере 180 гектар мәйдан били. Бүгенге көндә биредә эш кайный. Чөгендер игү буенча звено җитәкчесе, тәҗрибәле механизатор Касыйм Сатдаров «Морро» француз комбайны ярдәмендә шикәр чөгендере казытуга керешге. Якын көннәрдә тагын ике комбайн өстәләчәк.

**Х.НУРУЛЛИН.**



Әнис Хәмитовның хезмәт биографиясе күптән бер җайга салынган. Нык һәм нигезле итеп салынган. Казан техник училищесын тәмамлап ул мөстәкыйль эшли башлый. Шунда ук «Норлатнефть» НГДУсының автоматлаштыру цехында, 1988 елдан бирле слесарь хезмәтен үти һәм сайланган юлының дөреслеген аңлый. Шул вакыт дәверендә Әнис Ленардович зур тырышлык белән фидакарь хезмәт итә, һәр эштәгечә профессиональ осталык серләрен җентекләп өйрәнә. Шул һөнәренә өстәп эретеп ябыштыручы һөнәрен үзләштерә һәм кирәк булганда аны практикада да куллана. Шуңа да Әнис Хәмитовның цех буенча профессиональ осталыкка конкурста җиңеп чыгуы һич тә очраклы түгел.

Рәсемдә: Ә.ХӘМИТОВ.
Н.КВАШНИНА фотосы.

## «ВЕТЕРАН» АРАЛАШЫРГА ЧАКЫРА

Җәйге каникуллардан соң район мәдәният йорты каршындагы «Ветеран» клубы үз эшен яңартып җибәрә. Клубның чираттагы утырышы 23 сентябрь көнне 17 сәг. кә билгеләнә.

«Исәнме, табиб! » - бу очрашу шундый лейтмотив астында узачак. Теманың актуальлеге бәхәссез, көз - нәкъ салкын тиеп авырулар чоры бит. Шуңа да табиб консультациясе бик тә ярап куячак. Охшаш язмышлар, мәнфәгатьләр, бетмәс - төкәнмәс мәшәкатьләр берләштергән өлкән буын кешеләренә үзара аралашу гына да зур уңай тәэсир китерүен дә онытмаска кирәк. Ә «Ветеран» клубы активында яшәү чорында файдалы чаралар күп җыелды: кызыклы кешеләр белән очрашулар, конкурслар, бергәләшеп кино карaулар, «Ветеран» хорында катнашу, көз нигъмәтләре тулы өстәл артында бергәләшеп чәй эчү һ.б. Ә «Ветеран» клубы советының быелга (аны җитәкләүне тынгысыз Комунэлла Владимировна Изотовага йөкләделәр) янә уннарча ниятләре, кызыклы чаралары бар.

Шулай итеп, «Ветеран» әле һаман күңеле белән яшь, очрашуга үз дусларын җыя. Клуб занятиеләре ай саен икенче сишәмбе көнне кич белән үтәчәк.

# Чәчүлек орлыкны тикшертер чак

## (Агрокүзәтү)

Хуҗалыкларда быел чәчүлек материал салып кую эшендә әллә ни зур тоткарлыклар булмады һәм бүген район буенча 10 мең тонна чәчүлек орлык бар инде. Әмма аны аерып кую белән генә эш бетми әле, мәшәкатьнең җаваплысы алда. Салынган орлыкны хәзердән үк калибрлап, тиешле таләпләргә җиткерү турында кайгырту, шул исәптән орлыкларны дәүләт орлык инспекциясендә тикшертү мөһим. Кызганычка каршы, 15 сентябрьгә район буенча барлык орлыкның өчтән бере генә анализга китерелде. Тикшерелгән кадәресенең 32 проценты беренче, 38 проценты икенче, 18 проценты өченче класс таләпләренә җавап бирсә, 12 проценты әлегә кондициясез.

Синдряков исемендәге хуҗалыкның тикшерткән орлыгы әлегә тулысы белән беренче класс таләпләренә җавап бирә. Кузнецов исемендәге, «Заветы Ильича» хуҗалыкларының да тикшерткән орлыгының өчтән икесеннән күбрәге - беренче класслы. «Киекле», Кузнецов исемендәге, «Дуслык» хуҗалыкларында әлегә тикшертелгән бар орлык та беренче-икенче класслы. Ә менә МСО ярдәмче хуҗалыгыннан китерелгән орлык фәкать икенче класслы гына, ә шактый зур өлеше кондициясез. «Әлмәт», «Рассвет», «Үрнәк», «40 лет Победы», «Родина»да, нефтебаза ярдәмче хуҗалыгында да орлыкның тикшертелгән кадәресе арасында беренче класслысы бөтенләй юк әле, шул исәптән «Үрнәк»тә орлыкның дүрттән өче, «40 лет Победы»да өчтән икесе өченче класслы гына, «Чирмешән»дә, «Родина» һәм М.Җәлил исемендәге хуҗалыкта кондициясез орлык шактый.

Чәчүлек орлыкны өстәмә эшкәртеп, тиешле кондициягә җиткерү, төрлечә алыштыру өчен булган орлыкны тиз арада тикшертү кирәк. Ә менә чәчүлек материалны анализга тапшыруны суза килүче «Алга», «Комбайн», «Татарстан», «Таң», «Кондырча», «Якты Күл», «Төрнәс»тә, шикәр заводы, сөт - май комбинаты, «Агрохимсервис», РСУ ярдәмче хуҗалыкларында соңыннан бик авырга килергә мөмкинлеген уйламыйлар ахрысы. Елның - елында бу эшне иң алдан башкарып куючы Хафизов исемендәге хуҗалык агрономнарының да быел пошмавы аңлашылмый.

Быел мул иген уңышы җыелу киләсе елда да шундый ук үрләргә ирешүне үзеннән - үзе генә гарантияләми. Шуңа күрә киләсе ел турында бүгеннән яхшылап кайгыртырга кирәк. Ә яхшы орлык - ярты уңыш дип белми әйтмәгәннәр.

## Хөрмәтле дуслар!




**1998 елның беренче яртыеллыгына газетага язылу игълан ителде. Язылу бәясе ярты елга 26.4000, өч айга - 13.200, бер айга - 4.400 сум.**

Район газетасына язылырга ашыгыгыз! Ул һәрвакыттагыча сезгә яңалыклар, хәбәрләр, кызыклы киңәшләр белән бергә атналык телетапшырулар программасын да даими бирен барачак.

# Айсылу

№2

ХАНЫМНАР, ТУТАШЛАР ӨЧЕН МАХСУС СӘХИФӘ


**Хатын - кызлар, сезнең өчен**

## Адрес үзгәрсә дә...

Халыкка көнкүреш хезмәте күрсәтү район производство идарәсенең Школьная урамында урнашкан Көнкүреш хезмәте йортында «фатир» торган трикотаж ательесы ачылуына 14 ел булганда өч хуҗа алыштырды. Башта трикотажчылар «Татшвейбыт» берләшмәсенә буйсындылар. Соңрак аларны Синдряков исемендәге хуҗалык сатып алды. Быелгы елдан трикотаж ательесы райпоның хәзерләүләр конторасы карамагына күчкәч, аның адресы да үзгәрде. Цех шикәр заводы поселогының Московская урамындагы җиденче кибет бинасына урнашты. Хәзер бу бинада эшләүче райпоның тегү цехы белән трикотаж ательесы тулаем бер коллетив тәшкил итә. Элек нигездә трикотаж әйберләр бәйләү һәм ремонтлау, соңрак, синдряковлылар карамагында булганда сарык йоныннан җылы юрган - матрацлар сыру белән мәшгуль булган коллективның эш спецификасы киңәйгән бүген. Алда телгә алынган эш төрләренә өстәмә рәвештә кышкы өс киеме тегелә, ремонтлана бирелә. Шулай ук урын - кирәк - яраклары, эш киемнәре дә тектереп була. Әлеге товарларга ихтыяҗы булган һәркем үзе килеп тә, 2 - 26 - 68 телефоны буенча да заказ ясый ала.

Ательe мөдире Л.Е.Кабанова әйтүенчә, бирелә барлык төр эшне башкару өчен мөмкинлекләр зур икән. Тегү һәм бәйләү машиналары, «Симак» һәм «Тойоте» кулдан эшләү аппаратлары бәйләү бар трикотажчылар карамагында.

- Хәзерләүләр конторасында йон булганда җепкә дә аптырамабыз шәт,- ди Лидия Ермолаевна.

Әйе, йон булганда, ательe элеккеге «танышлыклары» буенча йонны җепкә алыштыру, яисә тиз арада юдырту мөмкинлекләренә ия. Ә хәзерләүләр конторасы йонга аптырамастыр. Соңгы елларда контора халыктан йон җыюны оештырмау сәбәпле халык бу продукцияне урнаштыра алмый иза чигә иде. Быел ательe өчен йон кирәккәч, йонны җыймый булдыра алмаслар, димәк.

Шулай булгач, трикотажчыларның үз маркаларын югары тотуларын гына телисе кала. Шәт, сынатмаслар. Ни өчен дигәндә, ательe ачылуының беренче көненнән үк норлатлыларның трикотаж әйберләренә булган ихтыяҗын тулы канәгатьләндерә килде. Бүген дә бирелә балалар өчен жакет һәм юбкалар, костюмнар, свитерлар, гамашлар һәм башкалар бар. Барысы да җылы итеп, сыйфатлы бәйләнгән. Салкын кышта сарык йоныннан сырылган юрганнарга төренеп йокларга теләүчеләр да аптырамасыннар, ательега килсеннәр. Ательe исә үзенә мөрәҗәгать иткән һәркемне каршы алып, аның ихтыяҗларын тулы канәгатьләндерүне гарантияли.

**Р.ГИНЯЕВА.**



*Хәтфә келәм - яшел чирәм*
*Югалып, сызып бара.*
*Күзгә баккан сукмаклардан*
*Атлап килә кыз бала.*
*И сөйкемле кыз бала!*
*Атламый, йөзеп бара!*
*Әйтерсең күзге урманда*
*Яз кояшы елмая...*

## Сөйкемле буласыгыз килсә...

***Һәрвакыт сөйкемле булып күренү өчен хатын - кыз берничә минут кына булса да вакытын битен тәрбияләүгә багышларга тиеш. Һәм моның өчен кыйммәтле кремнар сатып алуның да кирәге юк. Кремдагы витаминнарны кухняда һәм суыткычтагы ашамлыклар да бик уңышлы алыштыра ала. Бүген, шул нисбәттән, һиндстан косметологларының киңәшләре белән танышып карыйк. Алар фикеренчә кыяр, лимон кавын һәм бәрәңге бит тиресен җитәрлек дәрәҗәдә тукландыру сыйфатына ия.***

### ЛИМОН



Иң элек бер лимон согына җылы су кушып «лосьон» ясагыз. Аннары кайнар суга манчылган тастымал белән яисә битне пар өстендә тотып, биткә кайнар компресс ясап алыгыз. Шуннан соң биткә әзер лимон лосьонын сөртеп егерме минут тотыгыз. Ахырдан битне җылы су белән юарга онытмагыз.

### БӘРӘҢГЕ

Юылган битне бераз пар өстендә тотып алыгыз. Аннан соң кабыгы әрчелгән бәрәңгене, үтәкүрелмәле телем - телем турап, биткә каплап чыгыгыз. Унбиш минут үткәч, җылы су белән юып төшерегез. Чи бәрәңгедән ясалган бу маска битнең нәфислеген сакларга ярдәм итә.

● *Хуҗабикәгә*

### Сырдан салат

Угычта уылган сырга саламлап туралган тавык ите, башлы суган, пешкән йомырка, уылган сарымсак салыгыз. Аннан соң каймак, тоз, туралган укроп сибеп, барысын бергә болгатыгыз. Салат өстен яшел укроп белән бизәгез.

Бер өлеш салат өчен 75 г.сыр, 25 - 30 г пешкән тавык ите, 1 баш суган, 1 йомырка, 2 г сарымсак, каймак, тоз һәм укроп әзерләгез.

**КИЕМНӘР ТАПЛАНСА...**

**Кара җиләк белән карлыган табын бетерү өчен киемне иң элек сабынлы суда юып алыгыз. Аннары әчегән сөткә яисә лимон кислотасы эретмәсенә салып тотыгыз. Инде тап бетмәгән очракта шул ук процедураны яңадан кабатлап, аннары порошоклы суда юып чайкагыз.**

**КИЕМДӘГЕ ТУҢДЫРМА (МОРОЖЕНОЕ)** табына, бер чәй кашыгы суга бер чәй кашыгы бура салынган эретмә сөртеп тотыгыз да, бераздан яхшылап юып чайкагыз.

**ШОКОЛАД** табын тозлы суда яисә нашатыр спирты эретмәсендә юып бетереп була.

**КЫЗЫЛ КАРЛЫГАН, КУРА ҺӘМ ҖИР ҖИЛӘГЕ** тапларын бер өлеш аш серкәсенә бер өлеш лимон согы кушылган катнашма сөртеп чистартырга кирәк. Аннан соң, гадәттәгечә, порошоклы суда юыгыз.

Киемгә яңа гына буялган **ЯШЕЛ ЧИРӘМ** табын одеколон сөртеп бетерергә мөмкин. Ә менә кипкән чирәм табын, 30 г одеколонга 10 г нашатырь спирты кушылган эретмә белән бетерергә киңәш ителә.

Кипкән **ЙОМЫРКА** табын щетка белән ышкып чистартырга мөмкин. Инде бу ысул белән бетмәгән очракта, бензинга манчылган салфетка белән чистартыгыз.

## БЕР сорауга-җавап

*Паспорт алганда мин үзем теләгән милләтне яздыра аламмы? Минем әти - әнием - күченеп килүчеләр. Кечкенәдән мин урыс телендә генә сөйләшәм, әти - әни телен белмим, ул милләтнең гореф - гадәтләре, традицияләре миңа ят.*

**Марина Г.**
**Казан.**

Русиянең «Гаилә кодексы»ннан чыгып, Сез әти - әниегез милләтен генә яздыра аласыз. Әти - әниегез икесе ике милләттән булса, икесенең берсен сайларга хакыгыз бар .

**(«Око» юридик агентлыгы).**

## Холестерин - «маньяк»

Балыкның һәр төре кәтлиттән файдалырак диләр. Чөнки 100 грамм кызылыкта һәм кәтлиттә дә, кыздырылган бөер, бавыр һәм мидә дә 2000 мг. гына исәпләнә. Сырда, мәсәлән, 110 мг.

Берләшкән Милләтләр Оешмасы каршындагы Бөтендөнья сәламәтлек саклау оешмасы күрсәткечләре буенча кеше организмына тәүлегенә 300 мг.нан артык (ярты кап сыер маендагы кадәрле) холестерин кермәсә теләсә нинди май да зыян итми икән.

Холестерин шактый күп тупланганда кан йөрешенә зыян китерә. Ул тарая башлаган кан тамырларын томаларга мөмкин. Нәтиҗәгә организмга инфаркт, инсульт һәм гангрена яный.

Белгечләр профилактик чараларны үз вакытында үткәргәндә кан составындагы холестеринны нормадан арттырмаска була диләр. Бәла шунда ки, күп кеше үз организмында холестеринның артык күп булуын инфарктттан соң гына белә. Ул тире астындагы май түгел бит - күренми. Холестеринны кисәтүгә кешеләр нигәдер бик аз игътибар итәләр. Дөрес аның микъдарын төшерүче дарулар бар. Алар кан составындагы холестеринны бөтенләй дә юк итәләр.

Көнбатыш илләрендә, мәсәлән, холестерин белән медицина гына түгел, азык - төлек промышленносте, авыл хуҗалыгы һәм сәүдә дә көрәшә. Америкадагы һәр укучы бала холестерин кайда күбрәк икәнен белә һәм йомырка тәбәсен бары тик үсемлек маенда гына кыздыра. Олы кеше организмындагы холестерин микъдары тәүлегенә 300 миллиграммнан артмаска тиеш. Ашамлыкның күпчелек төре холестеринга бай. Без ризык талымлап тормыйбыз - нәрсә бар шуны ашыйбыз. Шуның өчен түбәндәгеләрне истә тотыгыз. Яшелчә һәм җиләк - җимеш туклануыдагы төп ризыклар булырга тиеш. Диңгез балыгының файдасы гаять күп. Сарымсак һәм башлы суган да холестеринны киметә. Ә кыздырылган, ысланган ризыкларны шулай ук камыр ашларын, гомумән, бик аз ашарга кирәк. Шулай эшләгәндә «холестерин» дигән маньяк сезне харап итә алмас.

## Төш юрау

**Агым су аша йөзеп чыксаң, кайгыдан арынасың.**

**Коедан су алганны күрсәң - кияүгә чыгасың.**

**Төшеңдә еласаң, шатланасың.**

**Төшеңдә тауга менсәң, бәхетле булырсың.**

**Төшеңдә яшеллек күрсәң - тиз килә торган шатлык.**

**Төштә атка атлану - мәртәбәгә ирешү.**

**Төштә гармун тавышы ишетсәң, хәбәр була.**

**Төштә төрле җепләр күрү - юлга чыгу.**

**Төштә җеп эрләсәң, ерак җирдән якын кешең килә.**

## БУЛМАС ДИМӘ, ДӨНЬЯ БУ!

# БАЛ ҺӘМ БӨҖӘК ХИКМӘТЛӘРЕ

Көнчыгыш ырымнары буенча, «үгез» елы табигатьнең үзен генә түгел, кешеләрне дә сыный: Африка негрларын «Умарта туена» бал тамакае - бәләкәй кошчык алып килә. Ник дигәндә, аның бал күченә үз көче генә җитми. Ике аяклы ерткычлар умартаны туздыралар, ә теге хәйләкәр кошчык исә кортлардан авыз итү өчен шуны гына көтеп тора.

Шулай да безнең өчен кортларга һәм аларның кәрәздәге нәселенә караганда баллары тәмлерәк. Моннан тыш, балның кешегә биниһая көч - куәт бирә торган хасияте бар.

Әйдәгез, мисалны тарихтан китереп карыйк. Беренче бөтендөнья сугышында Англиянең батырылган «Лузитания» пароходындагы бик күп алтынны, байтак мәшәкатьләр чигеп тә, һич күтәрә алмаганнар. Йомшак скафандрда водолазлар чыдамаган, ә каты скафандрда исә, кем әйтмешли, күз күрә, тик кул җитми икән. Шуннан акыллы кешеләр водолазны ярты ел буена бал белән туендырырга, балны торган саен күбрәк ашата барырга киңәш биргәннәр. Зур сынау алдыннан һәркайсы иң соңгы норма - 700 грамм ( ә барлыгы алты потлы бер мичкә балны) ашаганнан соң водолазлар, йомшак скафандр киеп, диңгез төбенә төшә һәм аннан барлык алтынны күтәрә алганнар.

Шуңа күрә быел безгә, бик күп бал ашап кына да, бик күп эшләрне майтара алырга булыр.

Ә менә Мюнхенда яшәүче әүвәлге француз физигы Бруно Клоде туклану проблемасын бөтенләй башка ризык чыганаклары белән хәл итмәкче була. Клоде идеясе гап - гади: ул ачлык кичерүче «өченче дөнья» илләренә, үз үрнәгендә, бөҗәкләр белән тукланырга киңәш итә. Аның мисалына иярсәләр, янәсе, берьюлы ике куян тотыла - беренчедән, халык өчен азык - төлек мәсьәләсе чишелә, икенчедән, корткыч бөҗәкләргә каршы көрәш алып барыла.

Бруно Клоде Мюнхен рестораннарының берсендә бөҗәкләр белән сыйланырга тәкъдим итә. Әлбәттә, калын майонез һәм сыр катламы астындагы чикерткә белән он кортларының чын тәмен татуы авыррак булыр. Аннары, кайбер батыр батыр тамакайлар сүзенә караганда, бериш бөҗәкләрнең хитин тышчалары тамакны аз - маз сыдырып та алгалый икән. Аның каравы, аксымлы ашамлыкларның бик туклыклы булуын берничек тә инкарь итә алмыйсың.

Үзенең ашарга һәвәслеген «өченче дөнья»дан башкалар да күз уңыннан үткәрергә тиеш, дип саный француз галиме. Аныңча, һәркем үз өендә аксымга бай бөҗәкләр фермасын оештырса, бердә начар булмас бу. Бөҗәкләр файдалы да, тәмле дә, өстәвенә, ышанычлы нигъмәт тә бит алар. Мондый эшчәнлеккә кризис янамый, аңа валюта курсы төшүе дә куркыныч түгел. Тик чәйни бир шунда таракан канатларын, чытыр - чытыр китереп.

Әлеге ише ашамлыкны искә төшерү белән үзендә җирәнү тойгысы туган кешегә Б.Клоде үзен - үзе тәрбияләргә киңәш итә. Әйтик хәмерне иренләгәндә бөҗәк тәмен дә сынап карарга, авызга капканнан соң төкерергә кирәк. Әнә шулай итә торгач, бер елдан соң аңа тәмам күнегеп җитәсең.

Француз үзе корт йомыркалары һәм коңгызлар белән генә диярлек туклана. Галим раславынча, аның өч меңләп тарафдары бар. Моңа ышанмаска да булыр иде, Б.Клоденың «Тәмле һәм туклыклы бөҗәк ашлары» исемле китабы 700 мең данәдән артык тираж белән басылып чыккан һәм аңардан менә биш ел инде, кем әйткәндәй, уңышлы файдаланып киләләр икән.

**«Российская газета».**

## *Менә сиңа мә!*




Херсон шәһәрендәге китап йортының фәнни төркем хезмәткәре Владимир Мостовой кызыклы ачышка тап булган. Сәяси репрессия корбаннары эше белән танышканда, ул Карл Маркcның улы Херсонда 1938 елның 16 февралендә атылган икәнен белә.

Рейнгольд Карлович Марксны СССРның Эчке эшләр халык комиссариаты һәм прокурор атарга хөкем иткән. Хөкем карары мондый: «Немецлар арасында фашизмга өндәү һәм совет власте белән килешмәүчәнлек тудыру максатларында диверсия эше алып барган өчен». Тикшерү күрсәткәнчә, ул бу эш белән райпотребкооперация бүлеге мөдире булып эшләгәндә шөгыльләнгән. Атаклы кешенең улы һәм биш бала атасы булу да аны социалистик революциянең җәза кылычыннан коткарып кала алмаган. Әмма бу карар дөрес булмаган - Карл Маркcның улы 1974 елда Украинаның Югары суды тарафыннан реабилитацияләнгән.

**(«Деснянская правда» газетасыннан).**

# КОТЛЫЙБЫЗ!



*Яңа Иглай авылында яшәүче кадерле тормыш иптәшем, әтиебез, бабабыз **Әхтәм Зыятдин улы Хөсәеновка** 19 сентябрьдә 60 яшь тула.*

*Без аны туган көне белән чын күңелдән котлыйбыз. Аңа исәнлек - саулык, җан тынычлыгы, шатлыклы кадерле картлык телибез.*

*Тарыйсың да чал чәчеңне сыйпап:*
*Картаелды инде, диясең.*
*Килә минем шул чал чәчләреңнең*
*Һәрберсенә башым иясем.*
*Әткәй, әнкәй, синнән башка тагы*
*Кем бар шундый бала бәгырьле.*
*Кояш сыман әнкәй берәү булса,*
*Син дә безгә шулай кадерле.*

***Сиңа изге теләкләр белән тормыш иптәшең, балаларың, киленнәрең, кияүләрең, оныкларың.***


## Белдерүләр

### САТАБЫЗ

**1993 елгы ВАЗ - 21074, 5 баскычлы күчеш тартмасы, газ һәм бензинда эшләү өчен көйләнгән, 39 мең км. юл үткән.** Адрес: Вахитов ур., 3 - 6, тел. 2 - 19 - 96.

* * *

**Каравыл Тавында фундаментта йорт, участогы бар. Бәясе - килешү буенча**. Адрес: Нефтьчеләр ур., 2 - 26, (17 сәг. соң.)

* * *

**«Иж - Планета» мотоциклы, кыйммәт түгел**. Тел.: 5 - 27 - 66.

* * *

**1993 елгы ВАЗ - 2105**. Адрес: Дружба ур., 75 - 65. Тел.: 65 - 5 - 36, (17 сәг. соң.)

* * *

**1996 елгы ВАЗ - 21061**. Тел.: 65 - 4 - 65 (Н... коммутаторы аша)

* * *

**Ашыгыч рәвештә һәм арзан бәягә 3 бүлмәле фатир.** Адрес: Московская ур., 5 - 45.

* * *

**Иске Әлмәт авылында йорт**. Егоровага мөрәҗәгать итәргә.

* * *

**Яңа йомшак кәнәфиләр**. Тел.: 2 - 24 - 58.

* * *

**Азык комбинаты янында гараж.** Тел.: 65 - 3 - 02 (НУРБ коммутаторы аша)

* * *

**Щит йорт комплекты.** Тел.: 3 - 31 - 11.

* * *

**Горький урамында йорт**. Адрес: Космонавтлар ур., 27.

* * *

**1992 елгы «Муравей» мотороллеры.** Адрес: 60 лет Октября ур., 7 - 7, (17 сәг. соң.)

### ТӨРЛЕСЕННӘН

**«Казахстан», Т -150 тракторлары, «Нива» комбайны сатып алам.** 446818, Самара өлкәсе, Кошки районы, Рус Васильевкасы авылында Чигалинский В.А.га мөрәҗәгать итәргә.

* * *

**Яшь кыз сатучы эше эзли.** Тел.: 2 - 32 - 58 (8 дән 12 сәг.кә кадәр.)

* * *

**2 бүлмәле фатир ике берәр бүлмәлеләргә алыштырыла**. Адрес: 60 лет Октября, 9 - 13.

* * *

**Түбән Кама шәһәрендәге 2 бүлмәле фатирны - Норлаттагы шундый ук фатирга алмаштырам.** Тел.: 5 - 13 - 31 (19.00 сәг. тән соң)

* * *

**Барлык уңайлыклары булган 4 бүлмәле фатир - коттедж (бакчасы, йорт яны корылмалары) - 2 һәм 1 яки өстәмә түләп икешәр бүлмәле фатирга алмаштырыла яки сатыла.** Тел.: 2 - 11 - 26.

* * *

**ВАЗ машинасын «Газпром» РАОсы акцияләренә алыштырам.** Тел.: 5 - 36 - 60 ( 14.00 дән - 16.00гә кадәр.)

* * *

**3 кешелек гаилә яшәп торырга фатир яки үзәктән ягыла торган йорт эзли**. Тел.: 65-0-40, эшнеке 2 - 28 - 24.

**25 сентябрь көнне 18.00 сәг.тә район үзәк Культура йортында «Ильдан» фирмасы мехтан эшләнгән әйберләр күргәзмәсе һәм сату оештыра.**

**Кышкы киемнәрне алырга теләүчеләрне күргәзмәгә чакырабыз. Керү ирекле.**

***Аксеновның бизнес мәктәбе компьютер курсына кешеләр җыя.***

«53 нче СМУ» ОООсына мөрәҗәгать итәргә. Лицензия - Б - 19 №2008.


### Әчемлекләрне үзебез әзерлибез

#### *Гөлҗимештән - аракы*

7,5 литр кайнатып суытылган суга 2 стакан гөлҗимеш, 100 грамм чүпрә, 4 килограмм шикәр саласың. Әчеп, тонгач (3 айдан соң) чип - чиста аракы хасил була. Шланг аша иплəп кенә шешәгә тутыралар.

#### *Алма суыннан - сидр*

8 литр алма суына 2 килограмм шикәр һәм бер литр су салалар. Яхшылап болгаткач (шикәр эреп беткәч) суслоны шешәләргә тутырып , әчергә куялар. 7 - 10 көн буе әчетәләр. Нәтиҗәдә 5 - 11 градуслы шәраб өлгерә. Аның градусын 16 - 18 гә җиткерер өчен бераз аракы йә спирт кушалар. Эчемлек алтын - сары төстә, бераз әчкелтем була, аннан алма исе килеп тора.

# Алтын яратасызмы? Юкка!

-Иннегегезне үзгәртегез,ул сезгә килешми,энергетиканы кимете- дип киңәш бирде табиб.Аннары минем бизәнү әйберләремне тикшерде:

-Сезнең металлыгыз-көмеш,алтын белән бик артык мавыкмагыз, алар шулай ук организмны көчсезләндерә...

Без үзебезнең киемгә зәвыгыбызны теге яки бу ташларга,металларга,мәхәббәтебезне сәламәтлегебезгә бәйләп карарга күнекмәгәнбез.Ә бит алар арасында турыдан-туры бәйләнеш яши. Әгәр дә сезнең арада биоэнергетик бергәлек юк икән,вакыт узу белән андый зәвык-гадәтләр авыру тудыруга сәбәп булалар.

Өч-дүрт еллар элек теләсә кайсы кооператив ларегында бакыр беләзекләр сатып алырга мөмкин иде. Хәзер халык аларга карата суынды,ахыры. Кызганыч.Безнең организмга бакыр җитмәү мускулларның тиз арусына,баш авыртуына,ярсуҹанлыкка китерә.

Ә аның җиту-җитмәвен ничек белергә соң? Тәүлеккә кеше организмы 3 грамм бакыр таләп итә. Азык-төлек белән шул кадәр аласызмы-юкмы, моны бик җиңел ачыклап була: авырта торган теләсә кайсы җирегезгә «биш тиенлек» яки бакыр пластинка куегыз. Тиредә карасу эз калмаса, барысы да тәртиптә дигән сүз. Эз карарак булган саен җитмәүчелек зуррак була.Ә ни эшләргә соң? Солы әйберләре, чөгендер,җир җиләге күбрәк ашагыз.Болай да эшләргә була:авырткан җиргә пластинка куярга,беләзек кияргә,бакыр чыбык белән билне буарга һәм шул килеш 6-8 сәгать йөрергә. Бакыр организмга яхшырак сеңсен өчен,аны вакыт-вакыт чистартырга кирәк:утта кыздырырга һәм наждак кәгазе белән ышкырга.

Менә тагын бер сер,аның аңлатмасын әле берәү дә белми, әмма файдасы бөтен кешегә мәгълүм. Йөрәгегез авыртса, чәнчә бармагыгызга теләсә нинди ак металлдан,хәтта алюминий чыбык та ярый,балдак киеп йөрегез.Сул яктан авыртса-сул кулда,күкрәк тирәсе авыртса-уң кулда.Буыннар оеганда аларны төнгә фольга белән урау да яхшы-ул да бит алюминий металладан.

Алтын бөтен кешегә дә зыянлы түгел,киресенчә, ул күпләрнең организмына уңай тәэсир итә. Үз металлы булган очракта,әлбәттә.


БАШ МӨХӘРРИР **Р.Ф.ҖАМАЛИЕВ.**

МӨХӘРРИР **С.Н.ХӘЙРУЛЛИНА**

**Учредительләр: Октябрь район хакимияте һәм редакциянең хезмәт коллективы.**

**"Дуслык" район газетасы атнаның чәршәмбе, җомга, шимбә көннәрендә чыга, рус һәм чуваш телләренә тәрҗемә ителә.**

**Безнең адрес: 423000, Татарстан Республикасы, Норлат шәһәре, Карл Маркс урамы,19.**

**Телефоннар: баш мөхәррир - 2-12-14, 2-22-81, мөхәррир һәм авыл хуҗалыгы бүлеге - 2-22-51, Советлар һәм җәмәгать оешмалары тормышы, чуваш теленә тәрҗемә буенча мөхәррир - 2-10-44, җаваплы сәркәтип - 2-18-67, рус теленә тәрҗемә буенча мөхәррир - 2-14-16, бухгалтерия,реклама бүлеге, фотокорреспондент - 2-15-63.**

***Газета Татарстан Республикасының мәгълүмат һәм матбугат Министрлыгында 34 нче номерлы таныклык белән теркәлде.***

Ульяновск өлкәсе матбугат һәм мәгълүмат идарәсенең Димитровград типографиясе. Офсет ысулы белән басылды. Күләме - 1 басма табак. Тираж 2336 данә. Заказ № 8815.